| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01.06.2019 № 446

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Расларга:

1.1. Нурлат муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару тәртибен (1 нче кушымта);

1.2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыру өчен вәкаләтле Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлеген (2 нче кушымта);

1.3. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге һәм файдалылыгы күрсәткечләре исемлеген (3 нче кушымта).

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов

ТР Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 ел, 1 июнь, 446 номеры белән расланган карарына 1нче кушымта

**Нурлат муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген формалаштырганда һәм алып барганда барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала (алга таба текст буенча-исемлек).

2.Исемлекне формалаштыру һәм алып бару түбәндәге принциплар нигезендә гамәлгә ашырыла:

2.1. Исемлеккә кертелергә тиешле муниципаль контроль төрләре турында мәгълүматларга карата таләпләр бердәмлеге;

2.2. Исемлектә булган мәгълүматларның дөреслеге һәм вакытында актуальләштерелүе;

2.3. Исемлектә язылган мәгълүматның ачыклыгы һәм үтемлелеге.

3.Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары турында белешмәләр исемлегенә кертү өчен нигез булып муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен билгели торган яисә аны гамәлгә ашыру тәртибен һәм (яисә) шартларын үзгәртә торган норматив хокукый актлар тора.

4.Исемлек Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты карары беләнраслана һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

5. Исемлеккә түбәндәге мәгълүматлар кертелә:

5.1. Муниципаль контроль төре исеме;

5.2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләре бирелгән исеме, аларның урнашу урыны, телефон;

5.3. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органы вәкаләтләрен билгели торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актының, муниципаль норматив хокукый актның атамасы һәм реквизитлары.

6. Исемлекне Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге (алга таба - вәкаләтле орган) алып бара.

7. Исемлектә булган белешмәләрнең актуаль торышын тәэмин итү бурычы Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы җирле үзидарә органына (алга таба - Орган) йөкләнә.

8. Исемлектә булган мәгълүматларның актуальлеген тәэмин итү максатларында Орган, муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыруны билгели торган норматив-хокукый акт проектын килештерүгә (үзгәртүче) җибәргәннән соң бер эш көне эчендә вәкаләтле органга язма рәвештә хәбәр итүне тәэмин итә.

9. Әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән исәп объектлары турындагы мәгълүматларны үзгәрткәндә, җирле үзидарә органы тиешле мәгълүматларны үзгәрткәннән соң, өч эш көне эчендә, тәкъдим ителә торган үзгәрешләрнең хокукый нигезләрен күрсәтеп, исемлеккә үзгәрешләр кертү турында вәкаләтле органга гариза җибәрә.

Гариза белән бер файлга Word форматында муниципаль тикшерүнең тиешле төрен гамәлгә ашыруны билгели торган административ регламентның актуаль текстының электрон версиясе куела.

10. Вәкаләтле орган гариза алганнан соң өч эш көне эчендә исемлеккә тиешле үзгәрешләр кертү турында норматив-хокукый акт әзерләүне гамәлгә ашыра.

11. Әлеге Тәртипнең 2.6 пунктында күрсәтелгән норматив-хокукый акт үз көченә кергәннән соң, вәкаләтле орган яңартылган Исемлекне Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру өчен җибәрә.

12. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру каралган (башка норматив хокукый актның) Федераль законны үз көчен югалтуын таныганда, муниципаль контрольне гамәлгә ашыру каралган җирле үзидарә органы Федераль законның (башка норматив хокукый актның) үз көчен югалтуын таныган көннән өч эш көне эчендә бу хакта язма рәвештә вәкаләтле органга хәбәр итә.

13. Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән хәбәр алынганнан соң өч эш көне эчендә исемлеккә исәпкә алу объектын исемлектән төшереп калдыру максатында тиешле үзгәрешләр кертү турында норматив-хокукый акт әзерләүне гамәлгә ашыра.

14. Исәпкә алу объекты исемлегеннән төшереп калдырылган теркәү номеры алга таба файдаланылмый.

ТР Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының
2019 ел, 1 июнь, 446 номеры белән расланган карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлеге**

| Тәртип саны | Муниципаль контроль төре исеме | Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы җирле үзидарә органы исеме (урнашу урыны, телефон) | Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен билгели торган Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актның һәм Россия Федерациясе норматив хокукый актының исеме һәм реквизитлары |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Муниципаль җир контроле | "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ, Нурлат шәһәре, К. Маркс урамы, 12 йорт, тел. 8 (84345) 2-06-04, 2-36-21 | Җир кодексының 72 ст.; "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131 номерлы Федераль законның 15 ст. 35 п. |
| 2. | Муниципаль торак контроле | ТР Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте һәм торак-коммуналь хуҗалыгы бүлеге, Нурлат шәһәре, Совет урамы, 117 йорт, тел. 8 (84345) 2-06-88 | Торак кодексының 14 ст. 9 п.; |

ТР Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының
2019 ел, 1 июнь, 446 номеры белән расланган карарына
3 нче кушымта

**Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге һәм файдалылыгы күрсәткечләре исемлеге**

Күрсәткечләр:

1. *еллык күрсәткеч*: **муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда узган елга карата профилактик чаралар санының үсеше, %.**

V= A/B х 100 %

А – агымдагы елда үткәрелгән профилактик чаралар саны

В – узган елда үткәрелгән профилактик чаралар саны

*2.еллык күрсәткеч*: **төзекләндерү кагыйдәләрен бозган очракта юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү фактларының кимүе, %;**

V = (A / B –A1 /B1) х 100

А1-агымдагы елда төзелгән актлар (беркетмәләр) саны, бер.;

В – планлы рәвештә узган ел үткәрелгән рейд тикшерүләре саны (системалы мониторинг), бер.;

В1-агымдагы елда үткәрелгән рейд тикшерүләре саны (системалы мониторинг), бер.

*3.еллык күрсәткеч*: **муниципаль районда контроль төрләренең гомуми саныннан аларны гамәлгә ашыру буенча административ регламентлар кабул ителгән муниципаль контроль төрләре өлеше, %.**

V= A/B х 100 %

А – муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча кабул ителгән административ регламентлар саны;

В - муниципаль контрольнең расланган төрләре.